Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Оет торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

29.03.2024 № 3

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының, 17.12.2021ел 29нчы номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында карарына таянып, 2023 елның 29 ноябрендәге 3 номерлы "2024нче елда Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Оет авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 632 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны сарыф итүнең конкрет юнәлешләренә юнәлдерү:

1) "Оет авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау"

2) "Оет авылы зиратына бункер сатып алу" белән килешәсезме" турында карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә:

1) "Оет авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау"

2) Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Оет авылы зиратына бункер сатып алу) турында 2023 нче елның 29нчы ноябрендәге 3нче номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы мәсьәләсе буенча 2024 елның 29 мартында гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде. Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия 152 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 77 кеше кертелгән. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 77 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде. Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Шыңар авыл җирлегенең Оет авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Оет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 29 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына, карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә 1) Оет авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау; 2) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Оет авылы зираты өчен бункер сатып алу) үзгәрешләр кертү турында" карарны кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов